# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында

1 статья. Бу Закон Татарстан Республикасы территориясендәге уен йортлары өчен «Уен бизнесына салым турында» Федераль закон нигезендә бердәм салым ставкаларын билгели.

2 статья. Уен бизнесына салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

уен йорты як буларак катнаша торган комарлы уеннар уткәрү өчен билгеләнгән һәр уен өстәле өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 2400 минималь күләмендә;

уен йорты оештыручы һәм (яки) күзәтүче буларак катнаша торган комарлы уеннар уткәрү өчен билгеләнгән һәр уен өстәле өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 200 минималь күләмендә;

һәр уен автоматы өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 90 минималь күләмендә;

һәр тотализатор кассасы әчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 2400 минималь күләмендә;

букмекер конторасының һәр кассасы өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 1200 минималь күләмендә.

3 статья. Уен бизнесына салым суммасының «Уен бизнесына салым турында»гы Федераль закон билгеләгән салым ставкасының минималь күләменнән арткан өлеше Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә һәм 1999 елда, 50 шәр процент итеп,

272

Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга бүлеп бирелә. Алдагы елларда салымны Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар арасында бүлүне чираттагы финанс елына Татарстан Республикасының бюджет системасы турындагы Татарстан Республикасы законы билгели торган нормативлар буенча башкарырга.

4 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенен норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 27 мае
№ 2192